**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Иске Кората авыл җирлеге**
**Советы**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Совет Старохурадинского сельского поселения**
**Алькеевского муниципального района**

Адресы: 422898, РТ, Сиктерме-Хузангай авылы, ул. Мектеп ур., 15 Тел/факс: (84346) 73-4-03

Адрес: 422898, РТ, с. Сиктерме-Хузангаево, Школьная, 15 тел/факс: ( 84346) 73-4-03

РЕШЕНИЕ КАРАР

2021 елның 13 декабре 35№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Кората авыл җирлегенең архив фондларын формалаштыру турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 22 октябрендәге «Россия Федерациясендә Архив эше турында» 125-ФЗ номерлы Федераль закон, 2017 елның 20 июлендәге «Татарстан Республикасында архив эше турында» 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Иске Коратаавыл җирлеге Уставының 5 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Коратаавыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Коратаавыл җирлегенең архив фондларын формалаштыру турындагы нигезләмәне расларга
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән)көненнән соң икенче көнне үз көченә керә .
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында http://alkeevskiy.tatarstan.ru/адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Коратаавыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы Иске Кората
авыл җирлеге башлыгы: И.В.Кудряшов

ТР Әлки муниципаль районы
Иске Копата авыл җирлеге Советының
2021 елның 13 декабрендәге
35 номерлы карарына кушымта

# ИСКЕ КОРАТААВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ АРХИВ ФОНДЛАРЫН ФОРМАЛАШТЫРУ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 22 октябрендәге «Россия Федерациясендә Архив эше турында» 125-ФЗ номерлы Федераль закон (текст буенча алга таба - федераль закон), 2017 елның 20 июлендәге «Татарстан Республикасында архив эше турында» 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Иске Коратаавыл җирлегенең архив документларын формалаштыру максатларында эшләнгән..

2. Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр һәм терминнар:

-җирлекнең архив фонды үз эченә җәмгыятьнең матди һәм рухи тормышын чагылдыручы, тарихи, фәнни, социаль, икътисадый, сәяси һәм мәдәни әһәмияткә ия, Татарстан Республикасы халыкларының тарихи-мәдәни мирасының аерылгысыз өлеше булган, даими сакланырга тиешле һәм Россия Федерациясе Архив фондының состав өлеше булып торучы мәгълүмат ресурсларына керүче тарихи һәм даими рәвештә архив документлары җыелмасын ала;

- әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар Федераль закон белән билгеләнгән мәгънәдә кулланыла.

## 2. Архив фондларын формалаштыру

3. Җирлекнең архив фондлары район муниципаль архивында даими сакланырга тиеш.

4. Иске Коратаавыл җирлегенең архив фондларын формалаштыру Иске Коратаавыл җирлегенең җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар тарафыннан Әлки муниципаль районы муниципаль архивы һәм аның оештыру-методик җитәкчелеге белән килештерелгән срокларда гамәлгә ашырыла.

5. Җирлекнең архив фондларын сыйфатлы итеп формалаштыру, архив документларын саклау срокларын үтәү максатыннан җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, музей һәм китапханәләр:

5.1. эш номенклатураларын эшлиләр һәм район муниципаль архивына җибәрәләр;

5.2. даими һәм озак вакытлы (10 елдан артык) саклау эшләрен, шул исәптән шәхси составы буенча тасвирлама төзиләр һәм район муниципаль архивына җибәрәләр;

5.3. район муниципаль архивына сакланырга тиеш булмаган документларны юк итү турында акт төзи һәм килештерүгә җибәрә;

5.4. җирлекнең архив фондлары документларына фәнни-белешмә аппаратын булдыра һәм тулыландыра;

5.5. архив документларының, шул исәптән шәхси состав буенча саклау вакыты дәвамында сакланышын тәэмин итәләр.

6. Җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, музей һәм китапханәләр җирлекнең архив фондларын формалаштыру өчен кирәкле финанс, матди-техник һәм башка шартларны тәэмин итәргә, архив документларын саклауның норматив таләпләренә җавап бирә торган бүлмә бирергә бурычлы.

## 3.Район муниципаль архивына документлар тапшыру тәртибе

7. Җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, музей һәм китапханәләр документларының вакытлыча саклау вакыты чыккач, район муниципаль архивына даими саклауга тапшырыла.

8. Иске Коратаавыл җирлеге администрациясе, муниципаль оешмалар билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә муниципаль архивларга сайлап алу, әзерләү һәм тапшыруны тәэмин итәләр. Архив документларын даими саклауга сайлап алу, әзерләү һәм тапшыру, шул исәптән аларны тәртипкә китерү һәм транспортлау белән бәйле барлык эшләр дә документларны тапшыручы органнар һәм оешмалар акчалары хисабына башкарыла.

9. Даими саклауга документлар тапшыру, муниципаль район хакимияте карары белән расланган план-график нигезендә, ведомствоны саклау сроклары узгач, тиешле фәнни-белешмә аппараты белән тәртипкә салынган хәлдә гамәлгә ашырыла. Документларны даими саклауга вакытыннан алда тапшыру документларны югалту (юк итү) куркынычы янаганда, шулай ук җирлек хакимияте үтенече буенча башкарылырга мөмкин.

10. Документларны вакытлыча саклау сроклары, муниципаль архив белән килешенеп, документларны практик куллану кирәк булган очракта, озайтылырга мөмкин.

11. Оешмалар эшчәнлегендә барлыкка килә торган типлаштырылган идарә документлары исемлеге нигезендә, саклау сроклары күрсәтелеп шәхси состав буенча документлар, хезмәткәрләрнең шәхси эшләре, хезмәт килешүләре, хезмәткәрләрнең шәхси карточкалары, хезмәткәрләрнең шәхси счетлары, хуҗалык кенәгәләре һ.б. Иске Коратаавыл җирлеге хакимиятендә, муниципаль оешмаларда 75 ел дәвамында саклана, аннары, муниципаль район архивына тапшырыла.

12. Муниципаль оешмаларны үзгәртеп корганда архив документлары тәртипле хәлдә үзгәртеп корыла торган оешмаларның хокук дәвамчыларына тапшырыла. Шул ук вакытта муниципаль оешмалар, милек рәвешләрен үзгәртеп, үзгәртелгән очракта, архив документлары яңа барлыкка килгән оешмаларга-хокукый дәвамчыларга әлеге оешмалар һәм тиешле муниципаль архив арасындагы шартнамәләр нигезендә вакытлыча саклауга тапшырылырга мөмкин.

13. Җирлекнең җирле үзидарә органнарын, муниципаль оешмаларны бетергәндә, шәхси состав буенча документлар, шулай ук вакытлыча саклау

вакыты чыкмаган архив документлары муниципаль районның муниципаль архивына саклауга рәвештә керә.

14. Даими саклауга документлар кабул итү җирлек администрациясе һәм муниципаль районның муниципаль архивы тарафыннан эшләр кабул итү-тапшыру акты белән рәсмиләштерелә.

15. Документлар белән бергә өч нөсхә тасвирлама тапшырыла, бер нөсхәсе авыл җирлеге хакимиятендә кала.

## 4.Архив документларын куллану

16. Иске Коратаавыл җирлегенең җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, муниципаль оешмалар, музей һәм китапханәләр, тиешле архив документлары булган очракта, билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән архив белешмәләре яки гражданнарның социаль яклавына бәйле, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә ташламалар һәм компенсацияләр алуны күздә тотучы архив белешмәләре яисә архив документларының күчермәләрен кулланучыга бушлай бирергә тиеш.